РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» __08__ 2025г. №866

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 14.03.2022 № 173 карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән заказчыларның үзара эшчәнлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 05.04.2013 № 44-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы " муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 14.03.2022 ел, №173 карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган белән заказчыларның үзара эшчәнлеге тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1.5 нче пунктының 8 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контракт - язма рәвештә төзелгән һәм предметы товар кайтару, эш башкару, хезмәт күрсәтү (шул исәптән күчемсез мөлкәт сатып алу

яисә мөлкәтне арендалау) булган һәм тиешенчә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен муниципаль берәмлек исеменнән (муниципаль контракт) муниципаль заказчы тарафыннан төзелгән граждан-хокукый шартнамә;»;

1.2. 1.5 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Контракт - язма рәвештә төзелгән һәм предметы товар кайтару, эш башкару, хезмәт күрсәтү (шул исәптән күчемсез мөлкәт сатып алу яки мөлкәтне арендалау) булган һәм бюджет учреждениесе, муниципаль унитар предприятие йә башка юридик зат тарафыннан 05.04.2013 N 44-ФЗ санлы Федераль законның 15 статьясындагы 1, 2.1, 4, 4.1, 4.3 һәм 5 өлешләре нигезендә төзелгән муниципаль контракт йә граждан-хокукый килешү;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина